**Зур Ключи авыл җирлеге Советы**
**Яшел Үзән муниципаль районы**
**Татарстан Республикасы**

**КАРАР**

**«11» май 2021 ел** **№33**

Зур Ключи авыл җирлеге Советының 2007 елның 03 апрельдагы, 92 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Зур Ключи авыл җирлегендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге халкының җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашу хокукын тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясына, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Зур Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зур Ключи авыл җирлеге Советы **кара итте:**

1. 2007 елның 21 мартындагы 35 номерлы Зур Ключи авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Зур Ключи авыл җирлегендә гражданнар арасында сораштыру үткәрү һәм билгеләү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнарны сораштыруда сайлау хокукына ия җирлек халкы катнаша ала. Гражданнарның инициативалы проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча үткәрелгән сораштыруда уналты яшькә житкән инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителгән җирлек яки аның өлешендә яшәүчеләр катнашырга хокуклы.»;

1.2. 7 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә::

«3. Гражданнарны сораштыру, уналты яшькә җиткән инициативалы проектны тормышка ашыру - тәкъдим ителгән җирлек халкы яки аның өлеше инициативасы белән, әлеге инициативалы проектка ярдәм итү турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен үткәрелә.»;

1.3. 8 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Гражданнарны сораштыру билгеләү турында карар җирлек Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен Яшел Үзән муниципаль районының рәсми сайты (https://zelenodolsk.tatarstan.ru/ «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә файдаланырга мөмкин. Җирле үзидарә органнары гражданнар арасында сораштыру үткәрүне билгеләү турында җирлек Советының норматив хокукый актында билгеләнә:

1) сораштыру үткәрү датасы һәм сроклары;

2) сораштырулар үткәргәндә тәкъдим ителә торган (тәкъдим ителәчәк) сораштыру формулировкасы;

3) сораштыру үткәрү методикасы;

4) сораштыру кәгазе формасы;

5) сораштыруда катнашучы авыл җирлеге буенча минималь халык саны;

6) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып, гражданнар арасында сораштыру үткәрү очрагында сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе»;

1.4. 8 статьяның 3 пунктын төшереп калдырырга;

1.5. 23 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктына «үзидарә» сүзеннән соң «җирлек халкы өчен» сүзләрен өстәргә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Яшел Узән муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Зур Ключи авылы, Волостнов урамы, 16а йорт (җирлек администрациясе бинасы), Зур Ключи авылы, Волостнов урамы, 21 йорт (кибет бинасы) адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зур Ключи авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Зур Ключи авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С. Е. Комягин**